Муниципаль тур

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ
2023-2024 нче уку елы
11 нче сыйныф

ВАРИАНТ 2

Максималь балл – 61

I. ТЕСТ (20 балл)

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10
б	**4**	**3**	**2**	**3**	**3**	**2**	**4**	беркөнне	Ике нокта

II. Теоретик бирем.

Иярченле кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. (**6 балл**)

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Мәкаль һәм андагы хайван атамасын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) Авыр йөкне... тартыр.	1) керпе
Ә) ... аягын күреп булмый.	2) тычкан
Б) Араларыннан кара ... үткән.	3) үгез
В) Койрыгына бассаң, ... дә чыелдый.	4) мәче
Г) .... мөгезеннән эләктер.	5) ат

Җавап : **51423**

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Каз ул – **(кулга/өйгә/гаиләгә)** ияләштерелгән иң борынгы йорт кошларының берсе. Халык **(элек-электән/борынгы заманнан/борыңгы чордан)** **(чиксез / күп / гаять)** итеп каз асрарга яраткан. Беренчедән, аның мамыгыннан мендәр, түшәк-ястыклар ясаганнар. Мендәрләрдән башка авыл йортын күз алдына китереп буламы соң? Икенчедән, каз итеннән бик **(оста/уңган/дөрес)** итеп әзерләгән каз бәлешенә, каз тәбикмәгенә, какланган казга җитәме соң!

Каз – туйларның да төп **(күрке/асылы/гаяте)**. Чөнки кыз яки улның туен үткәргәндә пар каз **(борынгыдан/элеккеге/бер вакыттан)** инде туйның хөрмәтле күчтәнәче булган. Хәер, бүген дә туйларда каз чыгару йоласы яшәп килә әле. Бу **(йола/гадәт/очрак)** ул эш кенә түгел, матур итеп аралашу, күңел ачу, үзеңне күрсәтү чарасы да. *(Вакытлы матбугаттан)*

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Ак кәгазьдән каләм эзе тиз җуела,
Караны да, тушьларны да җуеп була.
Ташка язган сүзләрне дә еллар ала.
Күңелләргә язылган сүз мәңге кала.
Синең бурыч <....> күңелләргә сүзләр язу,
Язар өчен алтын сүзләр эзләп табу.
Әзер юлдан үз көеңә бару җиңел.
Тигез җирдә юл салу да авыр түгел. (*Э. Мөэминова*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

сызык

4. *Язар өчен алтын сүзләр эзләп табу* җөмләсеннән күчерелмә мәгънәле сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

Алтын сүзләр

5. Беренче куплеттан сыйфат фигыльләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

Ташка язган, язылган, үткән заман сыйфат фигыльләр, барлыкта.

яз – тамыр, -ыл, -ган – модаль кушымчалар

6. Шигырьдән ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

өчен, көеңә

7. *Ташка язган сүзләрне дә еллар ала* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз.
(2 балл)

Еллар – гади ия, ала – гади хәбәр, ташка язган – аергыч, сүзләрне – туры тәмамлык. Бу-ике составлы җәенке, тулы, гади хикәя җөмлә.

8.“*Күңелгә язылган матур сүз*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)